Милләтпәрвәр кунак : [Чаллының Үзәк китапханәсендә Татарстан Язучылар һәм Журналистлар берлекләре әгъзасы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Раил Гатауллин белән очрашу узды] // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 23 (3 апрель). – Б. 16.

# Милләтпәрвәр кунак

**Чаллының Үзәк китапханәсендә Раил Гатауллин белән очрашу узды.** Ул – Татарстан Язучылар һәм Журналистлар берлекләре әгъзасы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, «BELEM.RU» татар мәгарифе порталы җитәкчесе. Башкала кунагы шулай ук «Әдәби марафон» проектына нигез салучы, «Татнет йолдызлары» бәйгесен оештыручы, «ВКонтакте» социаль челтәренең татар теле өлешендә тәрҗемәчеләр координаторы, «Миллион татар» журналының баш мөхәррире буларак та билгеле.

Раил Гатауллинның яшь буынны милли рухта тәрбияләү, туган тел һәм милли мәдәниятнең киләчәге турындагы фикерләрен ирештерде. Шулай ук тормышыннан кызыклы вакыйгалар, хатирәләр белән уртаклашты.

Очрашу дәвамында Чаллы марафончыларының әйдаманы Резеда Гайнетдинова Раил Гатауллинга тормыш һәм иҗатына кагылышлы сораулар бирде.



Кунакның мавыктыргыч һәм гыйбрәтле җаваплары залга җыелган иҗат әһелләрендә, тамашачыларда соклану уятты.

«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз», – дигән мәкаль Раил Гатауллинга бик тә туры килә. Киләчәктә дә иҗатди уңышлары юлдаш булсын милләтпәрвәр шәхескә.